ШИМБӘ
6
МАРТ
1943 ел.
№ 53 (6775)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Азатлык сугышында татар халкы

Газетабызның бүгенге номерында татар халкының фронтовик татар сугышчыларына язган хаты урнаштырылды. Һәрбер сүзе мөкаддәс Ватанга, батыр Кызыл Армиягә, бөек полководец даһи Сталинга иң кайнар мәхәббәт, Советлар илендәге барлык халыкларга иң саф дуслык тойгысы белән сугарылган бу ялкынлы сәлам-хатны бүген иксез-чиксез фронтларда кулдан-кулга йөртеп укырлар. Җиңү дәрте белән ашкынып, үч тойгысы белән ярсып алга баручы батыр сугышчылар бу хаттан газиз ата-аналарының, сөйгән ярларының, җаннан кадерле балаларының тавышларын ишетерләр.

Татар халкы үзенең улларын бөек Ватан сугышына озаткан чагында туган илебезнең азатлыгын, бәйсезлеген соңгы тамчы канга хәтле сакларга наказ биргән иде. Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән татар егетләре бу сугышчан наказны барлык фронтларда да намус белән үтәделәр, үтиләр һәм үтәячәкләр. Орденнар белән бүләкләнгән күп меңнәрчә татар кызылармеецлары, командирлары, политработниклары, Салават Кәримов, Ильдар Маннанов, Фәрит Фәтхуллин, Геннадий Гобәйдуллин кебек Советлар Союзы Геройлары, Гани Сафиуллин, Якуб Чанышев, Зәки Котлыйн кебек татар генераллары халкыбызның тарихын, совет коралының данын югары батырлык үрнәкләре белән бизәделәр. Тиңсез каты сугышларда явыз дошманның җанлы көчен һәм техникасын кырып, шәһәр артыннан шәһәрне, авыл артыннан авылны Гитлер тырнагыннан коткарып алга барган көннәрдә, немец баскакларын массовый төстә илебездән куу башланган көннәрдә татар халкы үзенең баһадирлары белән горурлана. Ул аларга йөрәкне тирәнтен дулкынландыручы һәм тагын да зуррак җиңүләргә рухландыручы хатында болай дип яза:

— Без һәркайсыгызның ничек сугышуын күңел күзе белән күреп торабыз. Алмаз кылычларыгыз дошман башларын кисеп тәгәрәткән саен, корыч ядрәләрегез җир күтәрмәс явызларның кара йөрәкләренә барып кадалган саен без хәтсез куанабыз, бөтен ил белән җыелып чын күңелдән рәхмәтләр укыйбыз.

— Сез үлемнән курыкмыйсыз. Үлем үзе, сезнең ут астында корыч калкан кебек нык торуыгыздан өркеп, артка чигенә.

— Сез тормышны яратасыз, һәм тормыш сездән аерылмас. Тормыш сезнең белән, халык сезнең белән, Сталин сезнең белән, иптәшләр!

Татар халкы үзенең улларын шушы ирекле тормыш өчен, халык эше өчен, Ленин—Сталин байрагы астында бөтен совет халкы белән берлектә батырларча сугышырга, туган илебезнең газиз туфрагын ерткыч фашистлардан тәмам арчып бетергәнче сугышырга, явыз дошманнан рәхимсез үч алырга чакыра:

«Син, ул канга туймас албастыларны никадәрле күбрәк кырсаң—җиңү бәйрәме шул кадәр тизрәк килер.

Йөз немецны теге дөньяга озаткач туктап калма, йөз дә беренчесен мушкаңа ал! Йөз түбән капландырып төшер мәлгуньне!

Ятим балаларның күз яшен, тол хатыннарның аһзарын, бәхетсез аналарның ләгънәтен, хәсрәтле карчыкларның каргышын бомбага салып, минага кушып, дошман өстенә яудыр!».

Бу сүзләрдә барлык совет халыкларының теләкләре һәм тойгылары чагыла.

Совет кешеләре, кайсы гына милләттән булмасыннар, нинди генә телдә сөйләшмәсеннәр, кайда гына яшәмәсеннәр, аларның барсы да туган илебезне гитлерчы юлбасарлардан тазартып бетерү теләге белән, явыз дошманны җиңү теләге белән яшиләр, көрәшәләр.

— Барысы да җиңү өчен!

Шушы мөкаддәс тойгы белән дәртләнгән татар халкы үзенең фронтлардагы батыр уллары белән бергәләп, бөек полководец иптәш Сталин каршына басып тантаналы вәгъдә бирә:

— Без быел фронт өчен кирәкле корал һәм сугыш припасларын үткән елгы саннан ике өлеш артыграк һәм фәкать яхшы сыйфатлы итеп җитештерербез!

Без быел үткән елга караганда, мулырак игән уңышы алып, дәүләткә тагын да күбрәк икмәк һәм башка продуктлар тапшырырбыз.

Кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә корал тотып сугышсак та, туган илебез өчен, аның азатлыгы, бәйсезлеге, намусы өчен җаныбызны аямабыз.

Туган илебезнең барлык җирен тәмам азат итеп бетергәнгә хәтле кылычларыны кынга салмабыз!

ФРОНТОВИК ТАТАРЛАРГА ТАТАР ХАЛКЫННАН

сәлам хат

Ак диңгездән алып Кара диңгезгә кадәр сузылган фронтларда туган илебезнең һәрбер карыш туфрагын җаннан кадерле күреп, күкрәк киереп саклаучы һәм һөҗүмгә күчкән гвардия полкларының һәм дивизияләренең алгы сафларында баручы татар егетләре! Данлыклы Кызыл Армиябезгә XXV яшь тулган көнне, гаскәрләребезнең гүзәл җиңүләре көннәрендә татар халкы Сезгә үзенең ялкынлы сәламен җибәрә.

Татар халкының курку белмәс, артка чигенмәс намуслы уллары һәм кызлары! Сезне хәләл сөте белән туендырган, җылы кочагына сыендырган шәфкатьле аналарыгыз, Сезгә үзләренең иң яхшы сыйфатларын биреп тәрбияләгән аталарыгыз. Туктаусыз алга барырга һәм явыз дошманнан рәхимсез үч алырга үзләренең фатихаларын биреп, язгы кояш кебек якты сәламнарын тапшыралар.

Аталарыгызның каны йөрәкләрегездә дошманга карата мәңге сүнмәс нәфрәт уты булып янсын!

Аналарыгызның мәхәббәте Сезне дошман укларыннан сакласын!

Батырлыгы әкият итеп сөйләнерлек, көйгә салып җырланырлык баһадирлар! Сездән үрнәк алучы, Сезнең белән горурланучы газиз балаларыгыз, үзләренең язмышларын, бәхетле киләчәкләрен сезнең кулга тапшырып, өмет һәм ышаныч белән тулы сәламнарын язалар.

Алып йөрәкле, арысландай гайрәтле ирләр! Болытлар өстендә булсын, тауда булсын, кырда булсын ерткычларга үлем китерүче асыл егетләр! Сезнең нурлы йөзләрегезне йөрәкнең якты түрендә кайнар мәхәббәт белән саклаучы сөекле ярларыгыз, исемнәрегезне телдә тәсбих итеп йөртүче күрше-колан, кардәш-ыруларыгыз — күкләрдәге йолдызлар санынча, дәрьялардагы сулар санынча күптән-күп сагынычлы сәламнарын җибәрәләр.

Совет илендәге барлык халыкларның вәкилләреннән торган батыр иптәшләрегезгә, юлдашларыгызга, олы һәм кече командирларыгызга—татар халкы үзенең иң яхшы теләкләрен, туганлык һәм дуслык сәламнарын күндерә.

Газиз улларыбыз һәм кызларыбыз!

Сөекле ирләребез!

Кадерле туганнарыбыз!

Барлык татар халкының өмете Сезгә текәлгән. Халык йөрәге сезнең белән тибә. Иртәнге сәгатьләрдә фронттан шатлыклы яңа хәбәрләр тыңлау өчен без барыбыз да бер үк минутта уянабыз. «Безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга баралар, туган җиребезне явыз дошманнан чистарталар», дигән күңелле хәбәрне ишеткән саен сулышларыбыз иркенәеп китә.



Без һәркайсыгызның ничек сугышуын күңел күзе белән күреп торабыз. Алмаз кылычларыгыз дошман башларын кисеп тәгәрәткән саен, корыч ядрәләрегез җир күтәрмәс явызларның кара йөрәкләренә барып кадалган саен без хәтсез куанабыз, бөтен ил белән җыелып чын күңелдән рәхмәтләр укыйбыз.

Менә егерме ай инде, фронт сызыгында каты сугыш бара.

Рәхимсез сугыш бу. Бөтен Европадан җыеп китерелгән башкисәрләргә каршы, иң явыз, иң мәкерле, иң ерткыч дошманга каршы сугыш бу.

Ләкин шушы туктаусыз гүләп торган ут давылы эчендә, өзлексез явып торган бомба, мина яңгыры астында, татар егетләре үзләренең якын туганнары белән бергәләп атакага ташланалар һәм юлбасарлар өерен туктаталар, кыралар, шәһәр артыннан шәһәрне, авыл артыннан авылны азат итеп алга баралар.

Азатлык көрәшендәге барлык халыкларның уллары белән җан-тән бер булып, терсәккә-терсәк, йөрәккә-йөрәк тоташып атакага баручы татар егетләре!

Сез үлемнән курыкмыйсыз. Үлем үзе, Сезнең ут астында корыч калкан кебек нык торуыгыздан өркеп, артка чигенә.

Сез тормышны яратасыз һәм тормыш Сездән аерылмас. Тормыш Сезнең белән, халык Сезнең белән, Сталин Сезнең белән, иптәшләр!

«Батыр егет—яу күрке», дигәннәр борынгылар. Безнең якташыбыз—Советлар Союзы Герое Ильдар Маннанов әнә шундый күркәле егет.

Безнең бер орудиебез урнашкан турыга дошманның дистәләрчә танклары килеп чыгалар. Туган ил өчен җаннарын да аямаучы безнең тупчылар бу тигезсез сугышта бер-бер артлы яраланалар. Туп янында Ильдар бер ялгызы кала һәм тупны бер үзе корып, бер үзе төзәп, дошман танкларына каршы бер үзе ата башлый. Йөз дә сигез тапкыр ата ул. Немец танкларын ватык тимер өеменә әйләндереп, яндырып бетергәнче ата.

«Батыр яуда беленер», дигәннәр борынгылар. Бер үзе йөздән артык гитлерчыны кырып салган якташыбыз — Советлар Союзы Герое Салават Кәримов әнә шундый батыр егет.

«Тәвәккәл таш ярыр», дигәннәр безнең бабайлар. Кырык гитлерчыга каршы бер ялгызы сугышып, җиңеп чыккан якташыбыз—Советлар Союзы Герое Геннадий Гобәйдуллин әнә шундый тәвәккәл егет.

Дан һәм рәхмәт халык баһадирларына!

Бөек азатлык сугышында татар халкы эченнән күтәрелгән гайрәтле лачыннарга, мәргән укчыларга, тәвәккәл разведчикларга, дошманның техникасын һәм җанлы көчен аяусыз кыручы бронебойщикларга, зенитчикларга, ир йөрәкле тупчыларга, миномет һәм пулемет уты осталарына, тутыкмас кылычлы атлыларга, кыю танкистларга, тау һәм диңгез сугышы пәһлеваннарына, дошманны кыручыларның, аның коралын җимерүчеләрнең барысына дан һәм рәхмәт!

Рәхмәт һәм дан Сиңа, большевик пулеметчы Әбрар Җәләлиев! Бер сугышта гына син

(ДӘВАМЫ 2 НЧЕ БИТТӘ)

ФРОНТОВИК ТАТАРЛАРГА ТАТАР ХАЛКЫННАН

сәлам хат

(БАШЫ 1 НЧЕ БИТТӘ)

йөздән артык фашистны кырып салуың белән, татар егетенең үз ватаны өчен изге көрәш кырында нинди батырлыкка, нинди гайрәткә сәләтле икәнен бөтен дөньяга таныттың.

Дан һәм рәхмәт Сиңа, дошманның 19 танкысын яндырып, кисәүгә әйләндергән Әхмәт Хәлимов.

Төньяк-Көнбатыш фронтта очучы Камалетдинов, үз самолеты дөрләп яна башлаган хәлдә, дошман сафларын бомбалаудан туктамыйча, бик күп немец солдатларын һәм офицерларын кыра. Көнбатыш фронтта танкист Әбуталипов үзенең дәһшәтле машинасы белән немецларның сугыш кирәк-яраклары төялгән 25 грузовигын, 6 орудиесен, 8 минометын һәм икейөзләп солдат һәм офицерларын юк итә.

Бөек ватан сугышы татар халкы эченнән бик күп геройлар тудырды һәм тудыра. Без аларны Москвага килү юлларында дошман танкларының атакасын туктаткан гвардеецлар сафында күрдек. Без аларны Сталинград янындагы әһәмиятле биеклекне дошманга бирмичә саклап алып калган баһадирлар сафында күрдек. Немецлар бу биеклеккә бөтен буйларына басып, автоматлардан туктаусыз атып, дулкын-дулкын ябырылып килделәр. Биеклекне саклаучы отделение командиры Михаил Кабрибов, һөҗүм итеп килүче фашистларның саны өч йөзгә якын икәнлеген күргәч, үзенең татарлардан, үзбәкләрдән, казаклардан торган ун сугышчысына болай дип эндәшә:

«Кулыбыздагы һәрбер штык саен утызар дошман туры килә. Кем дә кем курка икән, хәзер үк стройдан чыксын!»

Ләкин бер генә сугышчы да баскан урыныннан кузгалмый. Алар барысы да: «Үлсәк тә чигенмәбез!» дип ант итәләр һәм патроннары беткәннән соң да, штык белән сугышып, һәркайсы унар-унбишәр немецны кадап үтерә. Алар шулай батырларча сугышып, һәлак булалар, ләкин биеклекне немецларга бирмиләр. Менә шулай сакларга кирәк туган илне!

Үзләренең үлемнәре белән мәңге үлмәслек дан казанган гвардеецлар сафында без старшина Курмаевны күрәбез. Сугышның иң кызу чагында аның бер үзенә биш немец килеп ябыша. Куркусыз сугышчы беренче пулялары белән үк өч фашистны аударып ташлый, дүртенчесен яралый, бишенчесе кача. Бу бәрелештә каты яраланган Курмаевны тере килеш тотып алу өчен немец автоматчылары килеп чыгалар. Курмаев үзенең актык көчен җыйнап, билендәге гранатасын чишеп ала һәм күкрәгенә куя. Немец автоматчылары килеп аның өстенә ташлануга граната шартлый. Курмаев геройларча үлә, ләкин ул, немец автоматчыларын кисәкләргә теткәләп үлә.

Ватан сугышы көннәрендә өч меңнән артык татар кызылармеецлары, командирлары һәм политработниклары орденнар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

Дон буендагы далада өч сугышчы: рус егете Феодор Липатов, украиналы Степан Михно һәм татар егете Фәррах Бикбулатов кыр-ДЗОТ тыбызны саклыйлар. Көтелмәгәндә аларга каршы немецларның ике танкысы һәм кырыклап автоматчылары һөҗүмгә ташланалар. Совет сугышчылары, бу һөҗүмгә каршы тормыйча чигенгән сурәттә, дошманның күрше частебыз тылына үтеп керәчәген яхшы аңлыйлар. Өч сугышчының берсе дә каушап калмый, артка чигенми. Алар искиткеч батырлык, кыюлык белән сугышалар, һөҗүм итүчеләрнең яртысын кырып, бер танкны яндырып, калганнарын кире борылып качарга мәҗбүр итәләр. Өч рядовой сугышчы, карап торуга бик гади, ләкин фронт өчен гаять әһәмиятле участокны саклап алып калалар. Туган илебезнең һәрбер карыш туфрагын менә шулай сакларга кирәк.

Бу мисалларның һәркайсында СССР халыклары арасындагы сталинчыл дуслыкның җиңелмәс куәте бөтен тирәнлеге белән чагыла.

Бу мисаллар сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның ялкынлы сүзләрен күз алдыбызга китереп бастыралар:

— «Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып.
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлемез,
Без тынычта аттан артык эшлибез».

Татар халкы үз гомерендә килмешәк немец баскаклары белән беренче тапкыр гына очрашмый. Ләкин бу очрашуларның һәркайсында русларның һәм татарларның бердәм көче җиңеп килде.

Моннан дүрт йөз ел элек 1558—1582 нче еллардагы Ливон сугышы чорында, рус армиясе сафларында бик күп татар егетләре немецларга каршы көрәштеләр.

Көмеш иярле акбүз атларга атланып, озын сөнгеләрен, ай кылычларын кояшта ялтыратып Нарва шәһәренә бәреп кергән татар гаскәрләренең кыюлыклары турында ул замандагы немец тарихчылары котлары чыгып язганнар. Үзләренең гайрәтләре һәм кыюлыклары белән безнең бабайлар немецларның йөрәгенә дәһшәт салганнар.

1914—18 нче еллардагы немец империалистларына каршы сугышларда, тарихка «Брусилов прорывы» дип кергән һәм гаҗәп зур осталык белән башкарылган операциядә татар солдатлары рус армиясенең алгы сафында бардылар.

«Ора алмаган олы күтәрә»,—ди халык мәкале. Безгә каршы сугыш башлаган саен хурлыклы җиңелүгә очраган немец юлбасарлары, 1918 нче елда тагын бер тапкыр олы күтәреп, яшь Советлар илен канга батырырга теләп, поход оештырдылар.

Германия империализмы өчен бик күңелсез беткән 1918 нче ел сугышы Советлар илендәге халыклар дуслыгының көчен, куәтен тагын бер тапкыр раслады. Тарихи сабакларны һаман оныта килгән тинтәк немецлар гына ул сабакны оныттылар. Алар, үз танкларының кысрыклавы астында безнең көчләрне таркатырга уйлап, 1941 нче елда хыянәтчел сугыш башладылар. Ләкин бу юлы да алар җәһәннәм машиналары белән дә җимереп булмый торган каршылыкка, ныклы отпорга очрадылар.



Бөек полководец Сталин тирәсенә барлык совет халыкларының бердәм сугышчан лагерь булып туплануы немец оккупантлары йөрәгенә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә дәһшәтле курку салды. Немец ефрейторы Рудольф Вольтангның Германиядәге абзасына язган хаты шул дәһшәтнең җанлы шаһите булып тора: Ул болай дип яза: «Биредә безгә каршы татарлар бик күп сугышалар. Татарлар белән мин өнемдә генә түгел, төшемдә дә очрашырга теләмәс идем».

Татар халкының күз нуры кебек кадерле уллары! Сөйгән ярларыгызның Сезне фронтка озаткан чагында,

— «Куркак хатыны булып яшәгәнче,
Батырдан тол калу яхшырак»,—

дип җырлап, Сезне батырларча көрәшергә өндәп биргән наказларын намус белән үтәвегез өчен куанып бетә алмыйбыз. «Куркак егет ир булмас». «Курыкканга куш, коерыгы белән биш», дип куркаклыкка нәфрәт белән караучы татар халкы Сезгә, бабаларыгызның сугышчан традицияләрен саклавыгыз өчен иксез-чиксез рәхмәт укый.

Хезмәт сөючән тырыш табигатьле татар егете!

«Хезмәттә бәрәкәт», дип яшәгән безнең халык. Хезмәтне мактап ул әкиятләр сөйләгән, һөнәрләрне күтәреп җырлар җырлаган, ялкаулыкны мәсхәрәләп бәетләр әйткән. «Тырышкан ташка кадак кагар», дип әйткән безнең бабайлар. Шушы тырышлык, намуслы гадел хезмәт татар халкын ирекле илебездәге барлык халыклар белән аралаштырып, мәңге өзелмәслек дуслык һәм туганлык төеннәре белән тоташтырды.

Бөек рус халкының ярдәме белән, Ленин — Сталин партиясенең даһи җитәкчелеге белән татар халкы үзенең туган республикасын—Татарстанны төзеде. Элекке вакытлардан ук татар халкы культурасын саклап килә алды. Соңгы 25 ел эчендә ул танылмаслык дәрәҗәдә үзгәрде, үсте, алга китте. Безнең Татарстан алдынгы индустрия-колхоз республикасына, тоташ грамоталы илгә әйләнде.

Республикабыз меңнәрчә мәктәпләр, дистәләрчә техникумнар, күп кенә югары уку йортлары ачты. Син аларда укытучы булып та, агроном, врач, инженер булып та әзерләнә алдың. Республика синең өчен дистәләрчә театрлар мәйданга китерде. Син совет әдәбиятының һәм сәнгатенең иң матур үрнәкләрендә тәрбияләнеп, югары культурага ия булдың.

Син, даһи остазыбыз Ленин туып үскән, бөек язучы Максим Горькийны тәрбияләгән, Свердлов, Молотов, Киров, Бауман кебек халык улларын—ялкынлы революционерларны җитештергән, Шишкин кебек художникларга бай фантазия биргән һәм Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Галиәскәр Камал, Фатих Әмирхан, Шәриф Камалның бишеге булган Идел Йортта туып үстең.

Идел Йортның ирекле шәһәрләрендә, авылларында син үзеңнең сәләтеңә тиң хезмәт, талантыңа тиң профессия, мәхәббәтеңә тиң яр сайлап алдың.

Кайчандыр синең бабаларың:

— Дус-иш кирәк дөнья күтәргә...—дип җырлаганнар. Ул турылыклы дусларны син совет халыкларының тату семьясында таптың.

Кайчандыр синең бабаларың:

— Очар идем юк канатым... — дип моңаеп җырлаганнар. Совет власте сиңа болытлардан югары очарлык, кешелек культурасының иң бөек тауларына күтәрелерлек көчле канатлар үстерде.

(АХЫРЫ 3 НЧЕ БИТТӘ)

ФРОНТОВИК ТАТАРЛАРГА ТАТАР ХАЛКЫННАН

сәлам хат

(АХЫРЫ).

Ленин—Сталин партиясе синең халкыңны мәңгелек яктыга, бәхеткә, күңелле тормышка алып чыкты.

Менә шул бөек казанышларның барыннан да сине, синең семьяңны, синең халкыңны мәхрум итәргә теләп явыз дошман канлы балтасын күтәрде. Дошман синең язмышыңа хуҗа булырга, барлык якты өметләреңне пычракка салып таптарга, сөйгән ярыңны үзләренә кәнизәк ясарга, нараси балаңны буып үтерергә, иркен Идел Йортыңны каберлеккә, төрмәгә әйләндерергә омтылды.

Немецлар Советлар Союзындагы барлык ирекле халыкларны һәм шул рәттән безнең татар халкын да үтереп бетерергә теләделәр. Сталинград өлкәсендәге авылларның берсенә басып кергән кан эчүче немецлар татар хатыны Фатима Гыймадиеваның Марат исемле дүрт яшьлек улын ерткычларча җәзалап үтергәннәр. Алар аның нәни бармакларын бөрәмберәм тураганнар. Энесенең азаплануына түзә алмыйча шашып кычкырган ун яшьлек Фәтхине немец офицеры атып үтергән.

Калинин шәһәрендә торучы ак сакаллы Гали Сәйфуллинның уналты яшьлек кызын немецлар Германиягә коллыкка озатырга уйлыйлар. Кыз каршылык күрсәткәч аны атасы күз алдында фашист офицерлары атып үтерәләр.

Калуга шәһәрендәге Ибраһим бабай Нургалиев яралы кызылармеецны яшергәне өчен терелэй җиргә күмелә.

Донбасста эшләүче татар шахтерларын немец оккупантлары коточкыч ерткычлык белән үтерәләр. Белоруссиядә, Украинада, Балтик буйларында яшәүче татарлар һичбер гонаһсызга атылалар. Кырым, Кавказ җирләрендә безнең туганнарыбызның каннары, мәсхәрә ителгән сеңелләребезнең күз яшьләре елга булып ага. Боларны күз алдына китерсәң—тәннәр чымырдый, йөрәкне үч ялкыны көйдерә!

Совет кешеләренең каны өчен үч ал син немецтан!

Һәрбер тамчы кан өчен, һәрбер күз яше өчен, һәрбер киселгән гомер өчен үч ал!

—Үтер немецны!—дип ялвара сиңа карт әнкәң.

— Үтер немецны! — дип эндәшә сөйгән кызың.

— Үтер немецны!—дип сорый синнән нәни балалар.

Син, ул канга туймас албастыларны никадәрле күбрәк кырсаң—җиңү бәйрәме шул кадәр тизрәк килер.

Йөз немецны дөмектергәч, туктап калма! Йөздә беренчесен мушкаңа ал! Йөз түбән капландырып төшер мәлгунне!

Ятим балаларның күз яшен, тол хатыннарның аһ-зарын, бәхетсез аналарның ләгънәтен, хәсрәтле карчыкларның каргышын бомбага салып, минага кушып, дошман өстенә яудыр!

Канга туймас ерткычларны үләксә өеменә әйләндереп алга—көнбатышка баручы сафларыгызда безнең шатлыгыбыз, бәхетебез бергә атлый.

Батыр улларыбыз!

Сез фронтка киткән көннән алып байтак гомер узды, бик күп сулар акты. Сезнең көчле кулларыгызда очкыннар чәчрәтеп тимергә сугылган чүкечләр җирдә ятып калмадылар. Сез эшләгән станоклар кызу әйләнешен туктатмадылар. Киерелеп печән чапкан үткер чалгыларыгыз тупасланмады. Иркен кырларны гөрләтеп йөргән тракторлар, комбайннар эштән туктамадылар. Паровоз, пароход учакларында ут сүнмәде. Кадерле аталарыгыз, сезнең станокларыгыз янына басып, корал коярга керештеләр. Газиз әнкәләрегез колхоз кырларына юнәлделәр. Карт әбиләрегез сезнең өчен җылы бияләйләр, оекбашлар бәйләргә керештеләр.

Безнең шәһәрләребез йокы белмиләр. Кешеләрнең йөрәгендә хезмәт дәрте сүрелми.

Бөтен Татарстанга шаулаган токарь Фәйзи Абдрахмановның иҗат эзләнүләре—Сезгә җибәрелә торган сугыш припасларын ун өлеш арттырырга ярдәм итте.

Дәүләт Оборона Комитетының Кызыл Байрагы белән бүләкләнгән Н-че завод фрезеровщигы Бирюков, производство нормаларын ике мең проценттан артыкка үтәп, хезмәт фронтындагы батырлыкның иң . югары үрнәген күрсәтте.

Бөтенсоюз социалистик ярышта беренчелекне алган тырыш хатын-кызларның, корыч куллы ирләрнең, дәртле яшьләрнең йөрәкләрендә туган илгә кайнар мәхәббәт һәм дошманга нәфрәт ялкыннары дөрли.

Шушы мөкаддәс тойгы Арча районы «Кызылтау» колхозы комсомолецлары Габделхак Нуриев, Бәдигъ Абдуллиннарны хезмәт батырлыгына рухландырды. Алар, Татарстанда беренче буларак, хезмәт вакытын тыгыз файдалану юлы белән, ике терәнле сабан белән көненә бишәр гектар җир сөрделәр.

Шушы мөкаддәс тойгы йөз меңнәрчә ялкынлы патриотларны гадел хезмәт белән тапкан акчаларына самолетлар, танклар төзеп фронтка тапшыру хәрәкәтенә күтәрде. Мул тормышлы колхозчыларыбыз «Татарстан колхозчысы» исемле танклар төзү фондына бик аз вакыт эчендә 100 миллион сумнан артык акча туплап тапшырдылар.

Сөекле юлбашчыбыз, даһи полководецыбыз иптәш Сталинның Татарстан колхозчыларына белдергән рәхмәт һәм сәлам телеграммасы белән рухланып, республикабызның хезмәт ияләре үз акчаларыннан сугыш самолетлары эскадрильяларын төзү фондына өстәмә рәвештә 85 миллион сум җыеп тапшырдылар. Болардан тыш без ватан сугышы чорында оборона фондына 39 миллион сум бирдек һәм фронтовикларга 24 миллион сумлык төрле бүләкләр белән берлектә: 23.000 тун, 54.000 пар киез итек, 56.000 данә җылы чалбар һәм кием, 106.000 пар җылы күлмәк-штаннар, һәм башка әйберләр җибәрдек.

— Фронт сорый!—дидек без һәм бернәрсәбезне дә кызганмадык.

—Фронт сорый!—дидек без һәм атналар буе цехтан чыкмыйча эшләдек, кырдагы эш бетмичә яланнан кайтмадык. Барлык көчебезне бергә туплап яңа заводлар, яңа фабрикалар корып ходка җибәрдек.

—Фронт сорый!—дидек без һәм ун меңнәрчә гайрәтле егетләрне, сугыш эшенә өйрәтеп, сезгә булышырга озаттык.

Кадерле атабыз, сөекле юлбашчыбыз бөек Сталин каршына басып, сугышчан байракларыбызны үбеп ант итәбез.

Без быел фронт өчен кирәкле корал һәм сугыш припасларын үткән елгы саннан ике өлеш артыграк һәм фәкать яхшы сыйфатлы итеп җитештерербез. Без быел колхоз һәм совхоз басуларыннан үткән елга караганда мулрак иген уңышы алып, дәүләткә тагын да күбрәк икмәк, яшелчә, бәрәңге, ит, сөт; йон һәм май тапшырырбыз.

Кадерле улларыбыз һәм кызларыбыз!

Без нык ышанабыз, Сез дошманга тын алырга бирмәссез, аны көнбатышка таба тагын да куарсыз һәм немец басып алучыларны беткәнче кырырсыз.

Бүген без, Сезнең белән бергәләп, анабыз Идел ярларына басып, бабаларыбызның гадәте буенча Иделнең туфрагын үбеп, ант итәбез:

Кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә корал тотып сугышсак та, туган илебез өчен, аның азатлыгы, бәйсезлеге, намусы өчен җаныбызны аямабыз.

Кояш шаһит, Идел Йорт! Туган илебезнең барлык җирен тәмам азат итеп бетергәнгә хәтле кылычларны кынга салмабыз.

Яшәсен һәрбер карыш туфрагы, һәрбер үләне, суларының һәрбер тамчысы изге булган Ватаныбыз!

Яшәсен туган Кызыл Армиябез!

Яшәсен безне якты җиңү бәйрәменә алып баручы даһи полководецыбыз иптәш Сталин!

ХАТКА КУЛ КУЙДЫЛАР:

Казан энергокомбинат стахановчысы, кочегар **Зиннур Габдрахманов,** СССР Фәннәр Академиясенең действительный члены **А. Е. Арбузов,** Минзәлә районы, «Кызыл йолдыз» колхозы колхозчысы **Хаҗи Әхметов,** Казан мех фабрикасы стахановчысы, скорнячка **С. Әюпова,** ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре **Ф. Б. Бәдретдинов,** ВКП(б) ның Казан шәһәр комитеты секретаре **А. Г. Барышников,** Калинин МТС ының трактор отряды бригадиры **Сәет Бәширов,** Апас районы, «Тырышчы» колхозының ферма мөдире **Рәшидә Билалова,** Татарстан АССР ның халык артисткасы, РСФСР ның атказанган артисткасы, орденлы **Гөлсем Болгарская,** Казан шәһәренең 35 нче номерлы татар мәктәбе директоры **Гөлсем Гаффарова,** Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы председателе, СССР Верховный Советы депутаты **С. Х. Гафиятуллин,** ВКП(б) ның Өлкә Комитетының пропаганда буенча секретаре **С. Ш. Гаффаров,** Татарстан АССР ның атказанган врачы **Х. З. Гыйззатуллин,** Киров исемендәге завод стахановчысы **Галимә Гыйззатуллина,** Ленин исемендәге заводның инженеры, орденлы **И. И. Громова,** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе, СССР Верховный Советы Президиумы члены **Г. А. Динмөхәметов,** РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор **Нәҗип Җиһанов,** Чистай районы, Вахитов исемендәге колхозның кырчылык бригадасы бригадиры **А. Җаббарова,** Н-че завод стахановчысы, бригадир **Х. С. Зәйнуллина,** Казанбаш МТС ының трактор отряды бригадиры **Зәбир Зарипов,** ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре, СССР Верховный Советы депутаты **А. Г. Колыбанов,** химия фәннәре докторы, орденлы профессор **Гыйльми Камай,** язучы **Кави Нәҗми,** Казан тимер юлы машинисты, орденлы **А. Г. Крылов,** Алабуга совхозының сыер саучысы, Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашучы **М. И. Кузьменкова,** Әтнә районы, Киров исемендәге колхозның терлекчелек фермасы мөдире **Фатима Камалиева,** Кукмара районы, Сталин исемендәге колхозның умартачысы **Р. Латыйпов,** ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре **Луцкер,** Мөслим районы, «Дусай» колхозы председателе **Г. М. Мохтарова,** Морт МТС ы тракторчысы **Г. А. Мөхәммәтҗанов;** Буа районы, Киров исемендәге колхозның члены **О. Никитина,** Әлки МТС ы тракторчысы **Г. Нуретдинова,** Красный Бор районы, Кичкутан авыл советы председателе **М. Нәфыйкова,** Саба районы, «Игенче» колхозының кырчылык бригадасы бригадиры **Н. Нуриева,** Н-че заводның цех начальнигы **Протников,** ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре, СССР Верховный Советы депутаты **Хәбир Пазиков,** Тымытык МТС ы комбайнчысы **Р. Салахова,** Арча районы, «Кызыл ия» колхозы члены **Сафин,** Советлар Союзы Герое **С. П. Спирков,** Бондюг районы, «Кызыл йолдыз» колхозы члены **П. Сафиуллина,** Югары Ослон районы, Ворошилов исемендәге колхозның члены **М. М. Токарева,** Казан медицина институты профессоры, орденлы **Әбүбәкер Терегулов,** РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, орденлы язучы **Таҗи Гыйззәт,** Теләче районы, «Кызыл макса» колхозының дуңгыз караучысы **Харисова,** ВКП(б) ның Апас райкомы секретаре **Хәйруллин,** хезмәт ияләре депутатларының Тәкәнеш район советы башкарма комитеты председателе **Хисмәтов,** ВКП(б) ның Октябрь райкомы секретаре **Ямков,** Татарстан тел-әдәбият һәм тарих фәнни тикшеренү институты директоры **Х. Х. Ярмөхәметов** һәм башкалар, — барлыгы бу хатка 1.511.137 кеше кул куйган.

Совет Информбюросыннан

5 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ржевтан көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары 5—10 километр алга киттеләр. Немецларның күп санлы контратакалары алар өчен авыр югалтулар белән кире кайтарылды. Башка участокларда безнең гаскәрләр халык яши торган 42 пунктны алдылар, бик күп трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар. Кичә безнең частьлар Оленино шәһәрен алганнан соң сугыша-сугыша алга бардылар һәм шәһәрдән көньяктарак халык яши торган 10 пунктны алдылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть, көчле артиллерия әзерлегеннән соң, дошман окоплары линиясен алды. Дошманның контратакалары уңышсыз чыкты. Сугыш кырында 200 гә якын үтерелгән гитлерчылар һәм сафтан чыгарылган 3 танк калды

* * *

Харьковтан төньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары һөҗүм сугышлары алып бардылар. Безнең сугышчылар халык яши торган бер пунктны алган чакта 2 танкетка, бер броневик, 4 орудие, эре калибрлы 3 пулемет, азык һәм фураж склады кулга төшерделәр.

* * *

Льгов районында безнең гаскәрләр алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта 300 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 5 танкысы яндырылды һәм зарарланды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 9 орудие, 13 пулемет, төрле йөкләр төялгән 24 автомашина, миналар склады, снарядлар штабельләре һәм башка төрле сугыш милекләре бар.

* * *

Кубаньда Н-че часть сугышчылары, гитлерчыларның каты каршылык күрсәтүен бастырып, аларның ныгытылган позицияләрен алдылар. 100 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, 10 автомашина, 15 повозка, 3 миномет һәм 12 пулемет кулга төшерелде.

* * *

Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды февраль ахырында немецларның бер гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар 25 гитлерчыны, шул исәптән 5 офицерны кырып ташлаганнар һәм бер ягулык складын юк иткәннәр. Совет патриотлары 8 пулемет, 39 винтовка, 152 граната һәм 12.000 патрон кулга төшергәннәр.

* * *

Совет гаскәрләренең Ржев шәһәрен алулары гитлерчы идарәчеләр арасында буталыш тудырды. 3 нче мартта 15 сәгатьтә Берлин радиосы бик кыска гына итеп: «Немец гаскәрләре, фронт линиясен кыскарту максаты белән, Ржевны эвакуацияләделәр» дип хәбәр итте. Нәкъ 10 минут үтүгә шул ук Берлин радиостанциясе немец гаскәрләренең Ржевны эвакуацияләүләре турындагы хәбәрне юкка чыгарды. Соңга табарак, берлиндагылар инде берaз һушларына килгәч, Германия информация бюросының түбәндәге белдерүе игълан ителде: «Көнчыгыш фронтның үзәк участогында гаскәрләрне план тәртибендә яңадан оештыру барышында немец гаскәрләре фронт линиясенең Ржев шәһәре әйләнәсендәге алга чыгып тора торган дугасын да эвакуацияләделәр».

«Фронт линиясен кыскарту максаты белән» һәм «гаскәрләрне план тәртибендә яңадан оештыру барышында» немец гаскәрләренең чигенүләре турындагы бу Берлин белдерүләре безгә күптән таныш инде. Бу юлы да Берлин шулерлары безгә таныш булган һәм берничә тапкырлар капланган картаны яңадан ходка җибәрделәр. Шуның белән бергә, гитлерчылар Германия командованиесенең ни өчен бөтен кыш буена фронт линиясен «тигезләргә», «кыскартырга» һәм «күчерергә» мәҗбүр булганлыгын аңлатып бирергә теләмиләр.

Гитлерчылар немец-фашист гаскәрләренең үз ирекләре белән китмәгәнлекләрен, бәлки, башка күп шәһәрләрдән бәреп чыгарылган кебек, Ржевтан да Кызыл Армия тарафыннан бәреп чыгарылганлыкларын Германия халкына белдерүдән куркалар. Шуңа күрә алар совет—немец фронтындагы эшләрнең торышы турында планлы тәртиптә ялганлауларын дәвам иттерәләр дә.

5 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

5 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

4 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр, 15 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм 4 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Ржевтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 50 дән артык пунктны алдылар. Немецлар, пехота, танклар һәм артиллерия көчләре белән хәрәкәт итеп, нык каршылык күрсәтәләр. Безнең гаскәрләр дошманның оборонасын сындыралар һәм аңа уңайлы чикләргә ныгып урнашырга мөмкинлек бирмиләр. Н-че часть сугышчылары, елганы кичеп һәм халык яши торган бер зур пунктны алып, 300 дән артык гитлерчыны юк иттеләр, 7 орудие, 3 миномет һәм бер радиостанция кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр 6 танк, 60.000 патрон һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр бер көн эчендә 200 дән артык гитлерчыны юк иттеләр, дошманның 3 танкысын һәм берничә орудиесен сафтан чыгардылар. Пехота кораллары уты белән немецларның 3 самолеты атып төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар, каты сугышлар нәтиҗәсендә, 300 гә якын гитлерчыны кырдылар, дошманның 2 танкысын сафтан чыгардылар, 6 пулемет һәм танкка каршы ата торган 4 мылтык кулга төшерделәр. Икенче бер участокта совет сугышчылары контратакага күчкән дошманны алып ташладылар һәм ике взводтан артык дошман пехотасын юк иттеләр.

* * *

Харьковтан төньяк-көнбатыштарак Н-че часть немецларның бер батальон пехотасын тар-мар итте, танкка каршы ата торган 4 орудиесен, 11 пулеметын һәм сугыш припаслары төялгән 5 автомашинасын кулга төшерде.

* * *

Севск районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта немецлар, безнең гаскәрләрне тоткарларга маташып, танклар ярдәме белән контратака ясадылар. Сугыш нәтиҗәсендә дошманның 7 танкысы яндырылды һәм 3 танкысы зарарланды. Севск шәһәрендә безнең частьлар 515 кешене плен алдылар, 4 азык һәм фураж склады, күп кенә кораллар, сугыш припаслары һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Льговтан көнбатыштарак безнең частьлар, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, халык яши торган 10 пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның 1000 гә якын үле гәүдәләре калды. 650 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. 16 орудие, 5 автомашина, 30 повозка, бер азык склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды бер тимер юл станциясенә һәм дошманның бу станция янындагы поселокка урнашкан гарнизонына уңышлы һөҗүм ясаган. Бик каты сугышта партизаннар 100 гә якын немец солдатларын, бер майорны һәм ике обер-лейтенантны үтергәннәр. Совет патриотлары дошманның 5 складын, автомашиналар тора торган гаражын, 50 тонна ягулыгын юк иткәннәр, бер паровозны һәм 2 километр тимер юлны шартлатканнар. Партизаннар шактый күп трофейлар кулга төшергәннәр.

* * *

Төньяк-Көнбатыш фронтның бер участогында немецларның 290 нчы пехота дивизиясенең 502 нче полкыннан бер группа солдатлар плен алынды, 8 нче ротадан плен алынган обер-ефрейтор Георг Боберг болай диде: «Үткән ел көз көне безнең ротага Берлиндагы бер газетаның редакторы булган немец журналисты килде. Ул солдатларның сорауларын тыңларга һәм аларга җавап бирергә теләвен белдерде. Солдатлар аңа мондый сораулар бирделәр: «Сугыш кайчан бетәр?», «Кыш көне Көнчыгыш фронтта зур сугышлар булуны көтәргә мөмкинме?».

Редактор түбәндәгечәрәк җавап бирде: «Озакламый Германия армиясе Сталинград янында русларны җимерер һәм бу Волга крепостен алыр. Сталинградны алу—русларның бугазына ябышу булачак. Көньякта немецлар армиясе кышка кадәр Кавказны оккупацияләүне тәмам итәчәк һәм нефть чыга торган урыннарны алачак. Шуннан соң Көнчыгышта сугыш нигездә беткән дип санарга мөмкин булачак. Көньяк һәм Кавказ байлыкларына ия булганнан соң Германия гаять күп материал ресурслар алачак. Шул вакытта командование Көнчыгыш фронттан немец гаскәрләренең кимендә өчтән ике өлешен көнбатышка алачак һәм Англиягә хәл иткеч удар ясаячак. Көнчыгыш фронтта киләсе кышны зур күләмдәге сугышлар булмаска тиеш. Гитлер барысын да алдан күрде инде. Ихтимал, руслар җирле әһәмияте булган операцияләр ясарлар, ләкин алар бернәрсәне дә үзгәртерлек хәлдә булмаслар».

Хәзер, бу редактор турында искә төшергәндә, күп солдатлар: «Бу лыгырдык безнең кулга эләксен иде, без аны нишләтергә белер идек» диләр.

УКРАИНА

Язгы җилләр дәртле, җылы хәбәр
Алып килде безгә ерактан:
Күп калмады, диеп, Украинага
Котылырга канлы тырнактан.

Күреп синдә ничек көчәйгәнне
Мәңге сүнмәс көрәш ялкыны,
Көтә идек күптән без бу көнне
Өметләнеп хәсрәт аркылы.

Көтә идек батыр егетләрнең
Дошман явын тизрәк кырганын,
Көтә идек тагын хәтфәләнеп
Яшәргәнен синең кырларның.

Көтә идек данлы Днепрда
Дошманнарның каны акканын,
Бу дәһшәтле кара төн артыннан
Якты таңның балкып атканын.

Бүген менә штык очларында
Җиңү илтә сиңа батырлар.
Киң кочагын ачып үз улларын
Каршы ала тагын киң кырлар.

Коткарырга сине богаулардан
Кызганмыйбыз актык каныбыз
Ә син түккән изге кан-яшьләреңә
Озакламый үчен алырбыз.

Без алырбыз үчен явызлардан
Һәр авыл һәм һәрбер калаңның
Тере килеш утка ыргытылган
Һәр гөнаһсыз сабый балаңның.

Ышанабыз: тиздән кире кайтыр
Азатлык һәм бәхет еллары,
Тагын яңрар аяз, саф күгеңдә
Мәңге үлмәс шатлык җырлары.

Ә. ИСХАК.

Коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы законны озайтуга карата

НЬЮ-ЙОРК, 2 март. (ТАСС). Коралларны бурычка яки арендага бирү турындагы законның срогын озайту турында АКШ конгрессында закон проекты тикшерелә. Шул уңай белән сенатның чит ил эшләре комиссиясендә бу законны тормышка ашыру буенча уполномоченный Стеттиниус чыгыш ясаган. Ул үзенең докладында коралларны бурычка яки арендага бирү принципы нигезендә Кушма Штатлар тарафыннан союздаш илләргә ярдәм күрсәтүнең барышы турында сөйләгән.

Стеттиниус, Советлар Союзына ярдәм күрсәтү турындагы мәсьәләгә кагылып, түбәндәгеләрне белдергән: «Гитлер армиясен тоткарлау, ә соңыннан алып ташлау өчен Кызыл Армия файдаланган коралларның иң күп өлеше совет заводларында эшләнде. Ләкин шуның белән бер рәттән АКШ һәм Англия моннан 16 ай элек СССР га кораллар һәм материаллар җибәрә башладылар. Дошманга удар ясауда бу кораллар аз булса да үзләренең рольләрен уйнадылар. Шушы вакытка кадәр совет халкына материаллар җитәрлек санда җибәрелгәне юк әле. Без СССР га кораллар һәм материаллар җибәрүне арттыру өчен кулыбыздан килгәннең бөтенесен эшләргә тиешбез».

Стеттиниусның әйтүенә караганда, Кушма Штатлар тарафыннан шушы елның 1 нче январена кадәр Советлар Союзына 1.300 миллион долларлык материаллар җибәрелгән.

Шул ук елның 1 нче январена кадәр Кушма Штатлардан Англиягә 2.440 миллион долларлык кораллар һәм төрле материаллар озатылган.

Яңа Британия атавы суларында Япония корабльләре карванын юк итү турында Америка хәбәрләре

ЛОНДОН, 4 март. (ТАСС). Тын океанның көньяк-көнбатыш өлешендә союзникларның берләштерелгән көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, Яңа Британия атавы суларында булган сугыш нәтиҗәсендә Япония корабльләренең Лайга (Яңа Гвинея) бара торган кәрваны юк ителгән. Япониянең диңгез көчләре составында барлыгы 90.000 тонна чамасы авырлыкта 12 транспорт, 10 крейсер һәм эсминецлар булган. Бу транспортлар һәм карабльләр барысы да батырылганнар яки җитди рәвештә зарарланганнар. Япониянең 55 самолеты атып төшерелгән һәм бик күп самолетлары сафтан чыгарылган. Яңа Гвинея атавында операцияләр алып бару өчен билгеләнгән 15.000 япон гаскәрләре транспортлар белән бергә һәлак булганнар.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Американың су асты көймәләре Тын океанда сугыш вакытында Япониянең 133 пароходын батырганнар, 25 пароходын зарарлаганнар. Шулар өстенә яңадан 23 пароходның батырылган булуы ихтимал.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген һәм 9 нчы мартта—*„Печән өстендәге эт“*.

Зур драма театры. Бүген һәм 7 нчы мартта көндез һәм кич—*„Нашествие“*.

Яшь тамашачылар театры. Бүген—*„Москвичка“*. Кич 7 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан дәүләт филармониясе. 7 нче мартта Татар дәүләт академия театры бинасында *актрисы кичәсе*. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана. Билетләр сатыла.

„Электро“ — *„Җиңелмәслекләр“*.

„Унион“ — *„Юденичны тар-мар итү“*, кич—*„Таҗикстан улы“*.

„Чаткы“ көндез —*„Тимер һәм аның командасы“*, кич — *„Свекле кыз“*.

„Кызыл йолдыз“ — *„Котовский“*.

„Пионер“ көндез һәм кич—*„Өч мушкетер“*.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность, транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29, типография 36—60.

ПФ0172 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 357